**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Казаклар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче Иванай авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

21 ноябрь, 2023 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Иванай авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2023 елның 10 ноябрендәге 2 номерлы карары нигезендә, 2023 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Иванай авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Казаклар Чаллысы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм 1 төркем нвалидлардан, мобилизациялэнгэн гражданнар һәм аларнын гаилә әгзаларыннан гайре 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хэл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- торак пунктлар чиклэрендэ жирле әхәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау;
- чишмә суы жыела торган корылмага тозеклэндерү;
- ике берәмлектә янгын сүндерү гидранты алу һәм урнаштыру;
- торак пункт чикләрендә урамнарны яктырту челтәренә хезмәте күрсәтү;
- авыл жирлеге чикләрендә юлларны кардан чистарту һәм тигезлэп тору;

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Иванай авылы, Калинин урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы
вазифасын башкаручы Ф.Х.Хәсәншин